Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"2004 – 2010 елларга Татарстан Республикасы торак-коммуналь комплексын реформалау һәм модернизацияләү программасын раслау турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 3 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"2004 – 2010 елларга Татарстан Республикасы торак-коммуналь комплексын реформалау һәм модернизацияләү программасын раслау турында" 2004 елның 11 декабрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2005, № 7-8; 2008, № 8 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2009, 8 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 пунктта:

илле икенче абзацта татарча текст үзгәрешсез кала;

илле өченче һәм илле дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"коммуналь хезмәтләр күрсәтүнең сыйфаты тиешенчә булмаганда һәм (яисә) билгеләнгән вакыттан артык өзекләкләр белән күрсәтелгәндә, коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен үзгәртүне Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырырга;

торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтелү сыйфатына гражданнарның дәгъваларын карауны Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырырга;";

илле бишенче абзацта татарча текст үзгәрешсез кала;

2) 2004 – 2010 елларга Татарстан Республикасы торак-коммуналь комплексын реформалау һәм модернизацияләү программасына 3 нче һәм 4 нче кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга.

29

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2009 елның 24 декабре
№ 68-ТРЗ